ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге

Игән Баш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 15 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башкарма комитеты вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

1) Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын карап тоту (Игәнә - Баш торак пунктында махсуслаштырылган техникага-МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу) ;

2) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (Игәнә-Баш авылындагы юлларны кардан чистарту (йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

3) Игәнә-Баш торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар,яктырткычлар сатып алу);

4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

5)Игәнә-Баш авылы һәйкәлләрен ремонтлау (материаллар сатып алу). »

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 29кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 11кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 11 кеше «риза» позициясе өчен тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә Баш авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныргa.
2. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Игәнә Баш авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булман, вакытлы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, Украина

территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан 450 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә.:

1) Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын карап тоту (Игәнә - Баш торак пунктында махсуслаштырылган техникага-МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу) ;

2) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (Игәнә-Баш авылындагы юлларны кардан чистарту (йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

3) Игәнә-Баш торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар,яктырткычлар сатып алу);

4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтләре өчен түләү);

5)Игәнә-Баш авылы һәйкәлләрен ремонтлау (материаллар сатып алу). »

3. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга .http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,Сарман

муниципаль район Илексаз

авыл җирлеге башлыгы: Гильфанов Ф.М.